РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«26» июля 2021 е. Олы Кайбыч ав. № 55

2021 елның 1 яртыеллыгында Кайбыч муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТӘ:

1. Финанс-бюджет палатасы рәисе Михайлова Л.Г.ның «2021 елның 1 яртыеллыгында Кайбыч муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында» мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Кайбыч муниципаль районы бюджетының үтәлеше турындагы хисапны 2021 елның 1 яртыеллыгына керемнәр буенча 291 279 234,92 сум күләмендә, чыгымнар буенча чыгымнарның керемнәрдән 3 716 925,27 сумга артуы белән (бюджет кытлыгы) 294 996 160,19 сум күләмендә кушымталарда каралганча расларга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында http://kaybici.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы

А. И. Рәхмәтуллин